Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы

карары

2025 елның 30 октябре №100

«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 14 ноябрenә 16 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник поселогы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

**тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;**

**урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру;**

**су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;**

**җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;**

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;**

**тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;**

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;**

**каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;**

**торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү?**

**«РИЗА»** **«КАРШЫ»**

4. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев